Әйе, Ичалки Конезаводына еш кына балалар класслары белән бергә дә, аерым-аерым да экскурсиягә баралар; анда бик тә кызыклы һәм саулыкка да бик тә файдалы. Темников районында шундый матур эшләр башкаручыны беләбез. Ул - Митрял имамы Рафаиль Ханәфи улы Ялышев (рәсемдә улы Ильнур белән). Темник районында физик кимчелекле балалар очен интернат-йортта («Темниковский детский дом-интернат для детей с физическими недостатками») яшәүче балаларны оенә алып кайтып кунак итә һәм үзе асраган атка атланып иппотерапия дә үткәрә. Ә августта Удмуртиядә иппотерапия фестивале узган. Ижау ипподромы әлеге фестивальне «ВАЛТАУ» хәйрия фонды белән бергә оештырган. Фестивальдә атлар ярдәмендә сәламәтләндерү һәм тернәкләндерү белән шогылләнүче оешмалар катнашкан. Оештыручылар күнел ачу программасы әзерләгәннәр: атлар ярдәмендә чыгышлар күрсәткәннәр, атларда бушлай йөрү, фотосессияләр булган, шулай ук рәсем конкурсына йомгак ясалган.
Чыгыш ясаучы балалар тамашачыларны күреп, шатлык хисләре кичергәннәр. Белгечләр иппотерапиянен файдасы һәм мөмкинлекләре турында белешмә биргәннәр. Мөмкинлекләре чикләнгән балаларнын әти-әниләренә иппотерапевтлар, диетологлар, бала хокуклары буенча белгечләр белән аралашу, кызыксындырган барлык сорауларга жавап табу мөмкинлеге булган.
Иппотерапия - атлар яки пони ярдәмендә дәвалау алымы. Гәүдән тоз булсын дисән, атта йөрергә кирәк. Наркотикларга һәм алкогольгә бәйле затлар бу хайваннар белән күбрәк аралашса, тернәкләнү мөмкинлеге зуррак икән. Белгечләр полиомиелит, сколиоз, балаларнын церебраль параличы булганда атта йөрүнен нәтиҗәле булуын күптән исбатлаган. Ат ярдәмендә дәвалау үзәкләре бик күп илләрдә эшли. Ижау ипподромында да иппотерапияне кулланалар. Голнара Вәлиева, «Янарыш» газетасында болай ди: «Тренер Валерия Рябова әйтүенчә, атлар янында балалар тынычлана, доньяны танып белүләре жинеләя, атта йөргәннән сон мускуллары йомшара. Ул 10 елдан артык балалар белән шогылләнә. Безнен максат – баланы тынычландыру. Балалар, беренче чиратта, атта йөрергә дип килә. Шунлыктан алар атлардан курыкмыйлар. Ә без аларны ат остенә утырган килеш торле күнегүләр, хәрәкәтләр ясарга ойрәтәбез. Массаж ясаган вакытта, балалар елый, аларнын тәне авырта. Атта йөргәндә, баланын арка мускуллары табигый рәвештә ныгый, ләкин ул массаждагы кебек унайсызлык кичерми. Шулай ук куллары белән божраны ике кулы белән тотып барганда, аттан егылмас очен, аяклары белән

атны кысып утыралар. Аяк мускуллары да ныгый», – ди ул.

Наилә Насырова